БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 29 » март 2018 ел № 103

"Балтач муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары булдыру турында" 2013 елның 19 гыйнварындагы 6 номерылы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең сайлаулар турында гамәлдәге законнары таләпләрен үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә сайлау участогында, референдум участогында сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның максималь санын мең ярымга кадәр киметү максатларында, "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 2.1 пунктының "в" пунктчасы, 2.2, 2.3 һәм 4 пунктлары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. "Балтач муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары булдыру турында" 2013 елның 19 гыйнварындагы 6 номерылы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта "5 ел срок белән" сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Түбәндәге сайлау участоклары һәм Балтач шәһәр тибындагы поселогында яңа булдырылган сайлау участогы чикләре тасвирламасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

"9. 1068 номерлы участок.

Үзәк: Норма авылы, Казан урамы, 1 нче йорт, Норма мәдәният йорты бинасы, тел. 3-18-91.

Норма авылының М .Вахитов, Гагарин, М. Гафури, Ленин, М. Җәлил урамнары, Кариле авылының М. Мәһдиев, Мирная, Пионерлар, Татарстан урамнары (12 нче йорттан башлап 26 нчы йортка кадәр йортлар) керә";

" 29. 1088 номерлы участок.

Үзәк: Балтач штп, К.Маркс урамы, 7 нче йорт, “Балтач урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль белем бирү учреждениесе бинасы, тел.2-43-40.

Балтач шәһәр тибындагы поселогының С. Хәким, Таң, Г. Исхакый, Высоцский, Ш. Усманов, Арбузов, Г. Бәширов, Б. Урманчы, Татарстан (14 нче,16 нчы,18 нче, 20 нче йортлар), К. Якуб, Х. Сабиров, Ю. Гагарин, Вахитов, Ф. Яруллин, Молодежная, Ямашев, Г. Кутуй, Луговая, Г. Гыйлметдинов, Южная, Родниковая, Хәләл, Сугышчы-интернационалистлар, Белла Әхмәдуллина урамнары һәм Курмала, Көек торак пунктлары керә";

"30. 1089 номерлы участок.

Үзәк: Балтач штп, Нариман урамы, 108 нче йорт, "Балтач гимназиясе" муниципаль белем бирү учреждениесе бинасы, тел. 2-59-58.

Балтач шәһәр тибындагы поселогының Г.Тукай , Комсомол, Свердлов, Комаров, Пушкин, Сәидгалиев, Н.Исәнбәт, Я.Чанышев, Алмалы, Набережная, Чулпан, Энергетиклар, Х. Туфан, Лесная, Курченко, Королев, С. Сәйдәшев, Некрасов, 8 нче март, 1 нче май, Р. Зарипов, Г. Вәлиев, Г. Гозәеров, Н. Әхәтов, Озерная, Исаев, Туфан Миңнуллин, Кара-күл, Шушма, И. Юзеева, Лозинское поле, Нәүрүз, М. Мәрҗани , М. Мәһдиев, Г. Баруди, Г. Мөхәммәтшин, Цветочная, Чияле, Садовая урамнары.";

"31. 1090 номерлы участок.

Үзәк: Балтач штп, Ленин урамы, 45 нче йорт, "Балтач җирлекара үзәк китапханә" район муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе бинасы.

Балтач шәһәр тибындагы поселогының Ленин (1 нчедән 16 нчыга кадәр,18 нче йорт, 20 нчедән 36 нчыга кадәр, 38 нчедән 101 нчегә кадәр йортлар), Пионер, Киров, В. Булатов, Х. Такташ, Г. Гарифуллин, К. Насыйри, Космонавтлар, Мира, М. Җәлил, А. Алиш, Җиңүнең 50 еллыгы, Ф. Кәрим, Р. Фазлыев, Г. Ахунова, А. Фәйзи, Девятаев, Кол Шәриф, Сорнай, Совет, К. Нәҗми, И. Сәләхов, Салкын Чишмә, Родниковая, К. Маркс урамнары керә.";

" 32. 1091 номерлы участок.

Үзәк: Норма авылы, Казан урамы, 11 нче йорт, "Норма урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль белем бирү учреждениесе бинасы, тел. 3-17-22.

Нома авылының Г. Тукай, Т. Гыйззәт, К. Насыйри, Лицей, Молодежная, М. Садри, С. Садыйкова, А. Алиш урамнары, Кариле авылының Г. Әшрафҗанов, Г. Тукай, Дуслык, Заһидуллин, С. Сәйдәшев, Каенлык, Ф. Барыев, Төзүчеләр, Х. Туфан, Овражная, Т. Миңнуллин, Х. Такташ, Лесная, Г. Исхакый, Заправочная, Татарстан (1нчедән 11нчегә кадәр йорт) урамнары керә.";

"33. 1092 номерлы участок.

Үзәк: Ленин урамы, 154 нче йорт, "Факел" яшүсмерләр клубы бинасы, тел.2-43-77.

Балтач шәһәр тибындагы поселогының Төзүчеләр, Дуслык, Солнечная, Сөембикә, Мазһаров, Восточная, С.Садыйкова, Урожайная, Рафиков, Р.Галимуллина, Алкин, М. Искәндәров, А. Әсәдуллина, Искра, К. Тумашева, Балкыш, 9 нчы май, Х. Бигичев, И. Шакиров, Каенлык, И. Хисамов, Рәхимов, Т. Гыйззәт, А. Гыйләҗев, Тинчурин, Р. Яхин, Ф. Әмирхан, М. Кәрим, Н. Җиһанов, Октябрьнең 70 еллыгы, Г. Камал урамнары керә";

"34. Балтач шәһәр тибындагы поселогында яңа булдырылган сайлау участогы

Үзәк: Балтач штп, ленин урамы, 52 нче йорт, "Үзәкләштерелгән авыл клуб системасы" МБУсе бинасы (Балтач мәдәният үзәге), Тел.2-57-71.

Балтач шәһәр тибындагы поселогының Татарстан (1 нчедән 19 нчыга кадәр йортлар), Ленин (102 нчедән 158 нчегә кадәр йортлар), Речная, Ибраһимов, Н. Дәүли, З. Космодемьянская, Нариман, Медведев, Ленин (1а нчы, 1а/1 нче, 1б нчы, 3а нчы, 3в нчы, 3б нчы, 4г нчы, 17 нче, 19 нчы, 37 нче, 37а нчы йортлар) урамнары керә.".

2. Әлеге карарның үз көченә керүе 2018 елгы Россия Федерациясе Президентын сайлау буенча сайлау кампаниясе тәмамланганчы кичектерелә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә килештерү өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны "Хезмәт" район газетасында бастырып чыгарырга һәм интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://baltasi.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Р. И. Шакиров